Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Кызыл Бистә
авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР

№ 24 02.09.2022ел

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Кызыл Бистә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 5 мартендәге 7 номерлы карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, ТР Спас муниципаль районы Кызыл Бистә авыл җирлеге башкарма комитеты 2022 елның 31 маендагы протестын карап, ТР Спас муниципаль районы Кызыл Бистә авыл җирлеге башкарма комитеты карар чыгарды

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Кызыл Бистә авыл җирлеге башкарма комитеты 2022 елның 5 мартендәге 7 номерлы карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 2.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге оешмалар һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 1 өлешендә каралган хезмәтләрне күрсәтүдә катнашучы экспертлар тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелә.

1.2. Административ регламентны түбәндәге эчтәлекле 3.4.1 бүлек белән тулыландырырга:

«3.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүне алдан ук (актив) режимда күрсәтү очраклары һәм тәртибе.

Муниципаль хезмәт күрсәтүне алдан ук (актив) режимда бирү каралмаган.».

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Кызыл Бистә авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе А.В. Алиев